| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30 » 07 2021 № 239

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 ел, 13 октябрь, 646 нчы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел. 2 ноябрь, 880 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләрен һәм хезмәт күрсәтүләрен электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 ел, 13 апрель, 242 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 ел, 26 ноябрь, 651 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 13.10.2020 ел, № 646 карарына (12.01.2021 ел, №3, 01.07.2021 ел, № 208, 01.07.2021 ел, № 210, 27.07.2021 ел, №235 карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Билгеләнгән тәртиптә бинаны торак бина, муниципаль һәм шәхси торак фондының торак урыннарын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортларны, Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты».

1.2. 6 нчы кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта редакциясендә бәян итәргә.

1.3. түбәндәге эчтәлекле 1.32 пунктчасын өстәргә:

«1.32. Билгеләнгән тәртиптә бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»

1.4. 32 нче кушымтаны әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://Aksubaevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты финанс һәм мөлкәт
белән идарә итү буенча җитәкчесенен
беренче урынбасары И.И. Муратшин